**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**НУРЛАТСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

№ 590 | 25 июнь 2015 ел

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм күнекмәләр дәрәҗәсен бәяләүгә нормативлар, таләпләр буенча тест төрләрен (тестларны), нормативларны, таләпләрне үтәү буенча тест үзәге булдыру турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 11 июнендәге 540 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелышы, 2014, 25, 3309 статья) белән расланган «Хезмәткә һәм оборонага әзер» Бөтенроссия физкультура - спорт комплексы (ГТО) турында нигезләмәнең 26 пункты нигезендә, «сынау төрләрен (тестларны) үтәү буенча тест үзәкләрен булдыру тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Спорт министрлыгы боерыгы белән расланган, нормативлар, физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм күнекмәләр дәрәҗәсен бәяләүгә таләпләр һәм алар турында нигезләмә 01.12.2014 ел № 954/1, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында теркәлгән № 36215 от 26.02.2015 Г., «Татарстан Республикасы территориясендә «хезмәткә һәм оборонага әзер» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын (ГТО) гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 04.09.2014 № 1763-р карарына нигезләнеп

КАРАР БИРӘМ:

1. Г. С. Хөсәенов исемендәге ДЮСШ ДОД МБОУ спорт мәктәбенә тест уздыру үзәге вәкаләтләрен бирергә.
2. Тестлар уздыру үзәге җитәкчесе вәкаләтләрен Г. С. Хөсәенов исемендәге спорт мәктәбе директоры Ф. С. Гайнуллинга тапшырырга.
3. Г. С. Хөсәенов исемендәге ДЮСШ ДОД МБОУ спорт мәктәбенең тренер-укытучысы И. Д Беловны тестлар уздыру Үзәгенең баш судьясы итеп билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм күнекмәләр дәрәҗәсен бәяләү нормативларын, таләпләрен (алга таба - тестлау үзәге) үтәү буенча тестлау үзәге турында нигезләмәне расларга.

5. Тестлау үзәге җитәкчесенә 2015 елның 20 августына кадәр Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының гамәлдәге спорт объектлары һәм мәгариф оешмалары базасында тестлар уздыру урыннары исемлеген расларга.
6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасары А. С. Галәүтдиновага йөкләргә.

ТР Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Ә.К. Габдуллин